Кетеки тел бистәләре

Мәзәкләрне халыктан җыеп,
борынгы әдәбияттан файдаланып
әдәби телгә салучы
һәм китап итеп туплаучы

Гомәр Бәширов

Кетөки тел бистәләре

Мәзәкләр

Казан
Татарстан
китап
нәшрияты
1993



МАТУР БУЛГАЧ...

Бер карчык оныгы белән су буеннан бара икән, су кырыенда өч соры үрдәк, бер зәңгәрле-яшелле ата үрдәк күргәннәр.

— Шуларның кайсысы әти? — дип сораган әби.

Кечкенә бала соры үрдәкләрне күрсәткән:

— Әнә әтиләре! Алар өчәү, ә әниләре бер генә!

— Нигә алай дисең?

— Иң матуры шул ич. Матур булгач, әни була инде ул...

ИҢ МАТУРЫ МИНЕМ ӘНИЕМ

Кечкенә бала, базарда йөри торгач, анасыннан аерылып калган да елый башлаган. Шунда җыелган хатын-кыз аннан:

— Анаң ничегрәк киенгән, төсе-бите ничегрәк? — дип сораганнар.

Бала әйткән:

— Иң матур киенгән, иң матур әни минем әнием булыр...— дигән.

ЭШЛЕКЛЕ СОРАУ



— Бабай, әйтче әле, син кайчан бабай булдың?

— Син тугач, улым.

— Алайсам, моның өчен син миңа нәрсә бирәсең?..

3

КАЙСЫ МАТУРРАК?

Кечкенә кызый бүген генә кибеттән алган курчагын әнисенә китереп күрсәтә ди.

— Я, әйтеп кара әле, кем кызы матуррак? Синекеме, әллә минекеме?

— Синеңчә ничек соң?

— Синең кызың матуррак...

КЕТЕКИ ГЕНӘ...

— Әни, әнә радиода «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» дип җырлыйлар. Син дә мине шуннан алып кайттыңмы?

— Әйе, улым.

— Мин бит кыш көне туганмын. Ничек туңмадым икән?

— Сиңа бик җылы тун кидергәннәр иде.

Бала беравык тын калып торгач баш какты.

— Мин кетеки генә хәтерлим бугай әле ул тунны... 4

МЕНӘ ГАҖӘП!

— Әни, син кайда тугансың?

— Мин Казанда туганмын, улым!

— Әти кайда туган?

— Ул Мәскәүдә туган.

— Ә мин кайда тудым?

— Син Ленинградта тудың.

— Менә бит ничек! Өчебез өч шәһәрдә туганбыз, шулай да бер-беребезне табышып, туганлашканбыз. Ничек алай булды икән ул, ә?!

ЧӘЧ НИГӘ АГАРГАН?

Бер әни үзенең тиктормас малаен шелтәли ди.

— Бу шуклыгың, бу тыңлаусызлыгың белән чәчләремне агартасың инде син минем! — дип әйткән ди.

Малае әйткән ди:

— Алай булгач, әни җаным, кечкенә чагында син үзең дә бик тыңлаусыз булгансың икән.

— Ник алай дисең?

— Әбигә кара, бөтен чәче ап-ак!

КҮҢЕЛЛЕРӘК АВЫРУ...

Авырып ятучы әбисе янында оныгы бертуктаусыз тегесен-монысын сөйләнә икән. Апасы аңа:

— Әбиеңне борчыма! Нәрсә тәтелдисең анда бертуктаусыз! — дип кычкырган.

Кечкенә кызый моңа бик үпкәләп мышкылдый башлаган.

— Син беләсеңмени соң! Мин бит әбиемә авырырга күңеллерәк булсын дип сөйләшәм...— дигән.

РӘХМӘТНЕҢ ХИКМӘТЕ

— Әни, мин сиңа зу-ур рәхмәт әйтимме?

— Әйт, кызым, әйт!

— Ә син миңа зу-ур рәхмәт әйтерлек бе-рәр тәмле нәрсә бирәсеңме соң?..

ӨЧ ЯШЬЛЕК ӘБИ

Сәйдә үзенең әбисендә яши икән. Әбисе оныгын, оныгы әбисен бик ярата ди.

Күрше хатыны Сәйдәнең курчакларын күреп аларны бик мактарга тотынган:

— Әй-яй-яй! Кара нинди күп икән синең курчакларың! Бигрәк матурлар икән! — дигән.

Сәйдәнең моңа бик күңеле булган:

— Бу бит минем балалар бакчам! — дигән.

— Ә син үзең кем буласың? Тәрбияче апамы?

— Юк, мин аларның әбисе! — дигән Сәйдә.

ТИЗРӘК, ЯНӘСЕ

Әни кеше кечкенә кызы белән поездга утырырга ашыгалар икән.

— Әнә шул арттагы вагонга өлгерсәк, бик яраган инде,— ди әнисе.

Кызчык, киреләнеп, әнисен алга таба әйдәкли:

— Юк, юк, арттагысына түгел, иң алдагысына утырабыз. Минем апаларга тизрәк барып җитәсем килә!..

БЫЛТЫР КЫСКАНГА

— Хәйрулла, бәбкәм, ник елыйсың?

— Ишек яңагына бәрелеп башым шешеп чыкты.

— Я, күрсәт әле, кай төше? Кайчан бәрелдең?

— Кичә кич белән...

— Соң алай булгач, ник аның өчен бүген елыйсың?

— Кичә нигә елап торыйм ди? Ул чагында бит өйдә беркем дә юк иде...

БАЛА КҮЗЛЕГЕННӘН

Фәридә идәндә уйнап йөри иде. Менә аның тубы караваት астына кереп китте. Кызый карават астына иелде дә кинәт кире чигенде.

— Нигә тубыңны кереп алмыйсың? — диде анасы.

— Анда инде кап-караңгы, төн булган...— диде Фәридә.

ӘБИ НИГӘ ЙӨТКЕРӘ?

Кышкы салкын көннәрнең берендә ике кечкенә кызый курчак уйныйлар икән. Аш өеннән әбинең йөткергәне ишетелгән. Аның оныгы башын чайкап:

— Безнең әбигә бик каты салкын тигән,— дигән.

Әбине күрше кызы да бик кызганган.

— Бу салкында чыгып йөрмәскә кирәк иде аңа! — дигән.

— Беркая да чыкмады ул. Әнә анда «Кышкы бураннар» дигән рәсем эленеп торамы? Шуның астында утырып әби миңа оек бәйләде.



КУРЫКМЫЙ ИЧ ИНДЕ...

Әнисе кызын үгетли ди:

— И кызым, нинди зур үстең инде, ә өйгә ялгыз керергә әле һаман дә куркасың.

— Юк, әни,— дигән кызы.— Мин хәзер бер генә дә курыкмыйм инде. Әйдә, керик бергә, менә үзең дә күрерсең!

ҮЗЛӘРЕНӘ ОХШАГАННАР

Әбисенә кунакка илтеп куйгач, оныгы, сүзләрен йота-йота, иң зур шатлыгы белән уртаклашырга тотынды:

— Белә-сеңме, әби, безнең ике игезәк бәбиебез туды!

— Шулаймыни? Кара син, ә! Кемгә охшаганнар соң алар? Сиңамы, әниләренәме?

— Юк, алар бүтән беркемгә дә түгел, үзләренә-үзләре охшаганнар. Икесе нәкъ бер төсле!

КӨЙСЕЗ БАЛА

Бер көйсез бала булган. Ул анасына һич тынгылык бирмәгән ди.

Бер тапкыр шул бала су сорап еларга тотынган. Су биргәч, сөт сораган. Анысын да биргәч:

— Суга сөт кушып бир! — дип елаган. Анасы суга сөтне кушканнан соң:

— Инде сөтне судан аерып бир! — дип тагын да катырак еларга тотынган.

Шуннан соң анасы, тәмам аптырап, көйсезнең алдына ике җамаяк китереп куйган да әйткән ди:

— Монысына минем башым җитми! Мә, үзең аер! — дигән.

КУРЧАК ӘНИСЕ

— Кызым, курчагыңны күрмим. Кая куйдың?

— Мин аны йокы бүлмәсенә кертеп яткырдым. Хәзер телевизорда балалар карарга ярамый торган фильм күрсәтерләр.

— Ә синең үзеңә карарга ярыймыни?

— Мин курчакның әнисе бит. Әниләр белән әтиләргә карарга ярый...



ВАКЫТСЫЗ УЯТКАН

— И әби, нигә син мине шундый тәмле төш күргәндә уяттың инде, ә?

— Соң мин бит синең тәмле төш күргәнеңне белмәдем ләбаса!

— Ничек белмисең инде? Син бит минем белән янәшә чәкчәк ашап, тәмле конфет белән чәй эчеп утырдың!

ӘБИ ОЯДА

Тәрәзә каршындагы шомырт ботагында ике кош утыралар икән.

— Боларның берсе әти, берсе әни! — диләр балалар. Ул кошлар янына өченчесе килеп куна.

— Монысы апалары!

— Бәлки, әбиләредер?

— Юк, әби кеше ботактан-ботакка сикереп очып йөрмәс. Әбиләре ояда кечкенәләрне карый торгандыр...



ТУЙГА КАДӘР...

Ишегалдында йөргәндә әбине истә-оста югында ата каз тешләмәсенме! Әби кеше сызланып зарлана-зарлана балтырын уып утырганда аны оныгы да бик кызганган.

— Әбекәй, бик авыртамы? — дигән.

— Бик авырта, улым.

— Әби, син ничек тә түз инде. Туйга хәтле бер нәрсә дә калмас, төзәлер.

ТӨШТӘ НИ, ӨНДӘ НИ

Төнлә улы йокысыннан уянып мәчене янына чакырып алган.

— Нигә яныңа яткырасың мәчене? Авызыңа йоны керер,— дигән әнисе.

— Шаулама, әни! — дигән улы.— Без аларны кызык итәбез. Мин төшемдә бик күп тычкан күрдем. Хәзер без мәче белән йокыга китәбез дә ул аларның кирәген бирер! — дигән малай.





БАБАЙНЫҢ БУЕ

Биш яшьлек Рәмзия белән аның энесе Озынбай кушаматлы бабаларының буен үлчәп карарга булдылар. Тик ничек кенә итеп бабайның үзенә сиздермәскә? Энесе башын кашып торды да:

— Әһә! Белдем! — диде.— Бабай бүген базардан арып кайтыр да ял итәргә ятыр. Әйеме? Шунда шыпырт кына килербез дә...

— Таптың сүз! — диде Рәмзия.— Яткан килеш үлчәгәч ул инде, беләсең килсә, бабайның буе булмый, ә озынлыгы була.

ӘБИСЕ ҺӘМ ОНЫГЫ

Ашап утырганда кечкенә оныгы бабасына кисәтү ясады.

— Бабай, балалар шикелле, кашыгыңны ялама әле, алай килешми, әби андыйны яратмый.

— Соң, кызым, әбиең хәзер әле өйдә юк ич, ул безне күрми ләбаса!

— Юк, алай димә, бабай. Әби һәммәсен күреп тора, минем күзләрем белән күрә ул!

БАБАЙГА ЯРДӘМ

— Нигә син бабаңның ботинка шнурларын сүтеп алдың?

— Бабай бөгелә алмый бит, бәйләве бик кыен, дип зарлана.

БОРЫН КАНАГАЧ...

Нәсим урамнан борынын канатып кайткач, анасы аны бик каты орышырга тотынган.

— Белдем мин, белдем уеныгыз сугыш белән бетәсен, алдан ук сизеп тордым! — дигән.

Малай, мышкылдап:

— Белеп торгансың, ә миңа әйтмәгәнсең! — дигән.

3 Л-497

ЧЫН-ЧЫННАН



— Бабай! Әни әйтә, синең кай төшеңдәдер вак ташларың бар, ди.

— Дөрес, балакай, бар алар, бар, бөердә алар.

— Ә син аларны уйнарга биреп тора алмыйсыңмы?..

ҮЗ СҮЗЕ БАР...

Бакчадан алып кайткач әнисе улыннан сорады ди.

— Я, улым, ничек ашаттылар сезне балалар бакчасында?

— Мине ашатмыйлар, мин үзем ашыйм! — дип әйтте ди малай.

Әнисе, башын чайкап, «һм» дип елмаеп куйды ди.

ОШАТМАГАН



Бабасын пенсиягә озаткан җыелышка аның биш яшьлек оныгы да ияреп барган иде. Җыелышта сөйләүчеләр аның бабасы турында берсе артыннан берсе «лаеклы ялга озатабыз», «хөрмәтләп озатабыз!» дигәндәй әллә ничә тапкыр бер үк сүзне кабатладылар. Балага бу сүзләр бер дә ошамады. Күп кабатлый торгач, ул түзмәде:

— Безнең бабайны озатасы нитәсе юк! Ул әле тап-таза. Без аның белән икебез генә дә бик шәп кайтып җитәбез! — диде.

ЧЕТЕРЕКЛЕ СОРАУ

Гаяз әнисенә бик четерекле сорау бирде.

— Әнә күршеләр больницадан ике игезәк алып кайттылар. Ә нишләп безнең дә игезәк бәбиләребез юк?

Әнисе читкә карап елмайды да шаяртып кына котылырга булды:

— Күп белсәң, тиз картаерсың, дигән бабайлар.

Малайга бу җавап ошамады. Ул, кашларын җыерып, читкә борылды.

— Үзең дә белмисең икән әле,— диде.— Белсәң, минә минем дә ике игезәк сеңлем булыр иде...

16077

ХӘЗЕРГЕЧӘ

Бер әби үзенең оныгына кич белән йоклар алдыннан әкият сөйли башлаган.

— Борын-борын заманда бер авылда әби белән бабай булганнар. Аларның булган ди биш уллары, биш кызлары...

—Юк, алай түгел! — дигән оныгы.— Әби белән бабайның уллары-кызлары барысы да Казан белән Мәскәүдә, тагын әллә кайларда торганнар, ә бабай белән әбинең авылда ун оныгы булган...

ХӘЙЛӘКӘР КЫЗЫЙ

Чәй эчеп утырганда кечкенә оныгы әбисенә шундый сорау биргән:

— Әби! Нигә син борыныңа гел күзлек элеп куясың?

— Кечкенә әйберләр зуррак булып күренсен өчен, кызым.

— Әби! Алайса син миңа тәмлерәк әйбер биргәндә күзлегеңне салып тор, яме?

ЯРЫЙ ӘЛЕ УЯНДЫМ...

Бер малай гомерендә беренче мәртәбә анасы белән зоопаркта булган. Шул көнне ул төнлә яман кычкырып куркып уянган.

— Ни булды, нәрсәдән курыктың? — дип сораган анасы.

— Әле генә мине теге арыслан куып килде. Авызы менә мондый, тешләре мондый! Уянмаган булсам, беткәние баш...

ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ...

Мәрьям апалары ишекне бик каты ябып тузынып чыгып китте. Аның артыннан әниләре, йодрыгын айкап:

— Бар, бар! Күрәсем дә килми! Йөзләреңне йөз ел күрмәсәм дә үкенмим! — дип кычкырып калды.

Кечкенә кызлары нидер уйланып торды-торды да әнисе янына килде:

— Әни, әни, ә йөз елдан соң? Йөз елдан соң Мәрьям апага ачуланмассыңмы?..

ШАЯН ТЕЛ

Әби көн саен йоклар алдыннан ясалма тешләрен сулы стаканга салып куя икән. Моны күреп торган шаян оныгы:

— Әби, син иртәгә тикле телеңне дә шунда салып куй! — дип әйтте ди.

— Менә синең телеңне салырга кирәк стаканга! Юкса бит көне буена «нигә болай, нишләп алай?» дип теңкәмә тиеп бетәсең,— дигән әбисе. Бала ул кич өйдәгеләргә бер сүз дә әйтмичә шыпырт кына йөргән ди.

БАЛАЛАР КҮЗЛЕГЕННӘН

Кечкенә Рөстәм апасының көзге алдында бизәнүен карап тора. Менә апасы кашларын сөрмәләде, керфекләренә дә нидер сөртте, иреннәрен алсулатты.

— Я, матур булдыммы инде? — диде.

— Юк, бик үк матур түгел әле.

— Тагын нәрсә җитми?

— Борыныңны буйыйсың бар әле. Аннары нәкъ клоун буласың...

ҮЗЕ БЕЛӘ



Бер бәләкәй бала, уйный торгач, стаканны ваткан да почмакка барып баскан.

— Әни, мин почмакка бастым, ә син стакан ватыкларын җыеп ал! — дип кычкырган.

САБЫЙДАН ТУРЫ ХӘБӘР

Кечкенә малай табын янында самавыр килгәнне көтеп утыручы кунак абый тирәсендә бераз бөтерелгәләп йөрде дә, ияләнә төшкәч, аңа шундук сорау бирде.

— Абый, син шикәрсез чәй эчәр идеңме?

Кунак шаяртып кына җавап бирде.

— Була! Шикәрсез дә бик шәп китә яхшы чәй!

— Ә тозсыз аш, көйгән ипи ашыйсыңмы?

— Тукта әле, энекәш! Нигә шундый мәнсез нәрсәләр сорыйсың әле син миннән?

— Әни әйтә: бу абый алдына ни куйсаң, шуның барын да сыптыра, ди.

— Әһә! Шулаймыни әле! Ярый, «сый-хөрмәт»кә бик рәхмәт! — диде дә кунак кеше, ишекне каты гына ябып, чыгып та китте.

ӘТӘЧ КАЙЧАН ТУГАН?



Бер көнне ишегалдында уйнап йөргәндә әтәчне күреп Ирек дигән малай бабасына шундый сорау биргән.

— Бабай, әтәчнең дә туган көне бардыр, әйе бит?

— Юк аның туган көне, улым. Ул төнлә туган.

— Ә! Әйтәм аны ул күбрәк төнлә кычкыра...

ИКЕ МАЛАЙ

Ике малай урамда сугышып яталар икән. Зуррагы кечкенәсен акыртып кыйный ди. Кечерәк малай үзенең тегеңәр көче җитмәгәнгә бик хурланган. Күз яшьләрен сөртә-сөртә әйткән:

— Ярар, миңа да бер килеп кабарсың әле. Мин хәзер синнән ике яшькә кечерәк әле, ә тагын өч елдан мин синнән бер яшькә дәүрәк булырмын. Белдеңме? Менә шунда сине үкертеп дөмбәсләмәсәм, исемем Гата булмасын!



УННАН БИШ...

Көтүче үзенең улына көтүдәге атларны санап килергә кушкан. Улы санап килгән дә әйткән:

— Егерме бөтен уннан биш! — дигән.

— «Уннан биш» дигәнең нәмәкәй тагын?

— Тайлар!..— дигән улы.

КӨЧЛЕ ҖИЛ

Ике бала тәрәзәдән карап утыралар икән. Урамнан авыр сумкалар аскан бер апа белән айкала-чайкала бер ир кеше узып баралар ди.

— Нигә ул абый шулай чайкала икән?

— Көчле җил чыккандыр...

— Әнә апа кеше чайкалмый бит!

— Чайкалырга, аның сумкалары авыр ла!

КЕЧКЕНӘ АВЫЗДАН ЗУР СҮЗ

— И кызым, ялган сөйләргә ничек телең бара? Син бит әле бик кечкенә!

— Нигә, әни, зурларга ялганларга ярый икән, кечкенәләргә нишләп ярамасын?!

24

АХМАК ТЕЛЕННӘН ТАБАР

Ике кеше сөйләшеп торалар икән. Шуларның берсе әйткән:

— Хәзерге заман балалары бик күп беләләр, бик зирәкләр,— дигән.

Икенчесе әйткән:

— Сез аңа бик үк куанмагыз. Андыйларның зур үскәч акылы саега.

Боларны бер бала тыңлап торган икән. Шул әйткән:

— Алайса, абый, сез яшь чакта бик зирәк булгансыз,— дигән.

КЕМ КҮБРӘК БЕЛӘ?

— Син, малай актыгы, бик күп белә башладың әле!

— Юк, абый кеше, дөрес түгел! Сез үзегез бик аз белгәнгә күрә генә шулай тоела ул!..

25

САКАЛ

Кечкенә кызый ишегалдында уйнап торган җиреннән бабасына кычкырган.

— Бабай, син абый кешеләр генә сакал үстерә, ә апа кешеләрнең сакалы булмый дигәниең, әйеме?

— Әйе, дөрес.

— Юк, дөрес түгел шул! Әнә кәҗә — апа кеше бит, ә аның сакалы бар!

ЗООПАРКТА



Зоопаркның маймыллар асрала торган бүлеге янында кечкенә балалар үзара бәхәсләшәләр икән.

— Нигә орангутангны, төрмәдәге сыман, тимер рәшәткә эчендә тоталар икән?

— Аны шулай тәрбиялиләр. Бераздан ул аннан кеше булып чыгарга тиеш...

АЧЫК ҖАВАП

Яшен яшьнәгән вакытларда кечкенә малайга шундый сорау биргәннәр.

— Синеңчә ничек? Нишләп без яшен яшьнәгәнне алдан күрәбез дә нигә күк күкрәвен бераздан гына ишетәбез?

— Нигә аптырадың аңарга? Безнең бит күзләр алдарак, колаклар арттарак...



КҮЧҮ ЧОРЫ



Әти кеше әллә шаяртып, әллә чынлап бер көнне хатынына сәер сүз ычкындырды.

— Беләсеңме, безнең малайның хәзер күчү чоры башланды, ахрысы.

— Каян беләсең?

— Баларак чагында ул синең итәгеңә үреләиде, ә хәзер минем кесәгә үреләә...

КЫСАН БУЛСА ДА ТУГАН ӨЙ

Яз көне әле генә йомыркадан чыккан сары чебеш йомырка кабыгына карап борынын җыерган ди.

— Әбәү, бигрәк кечкенә инде бу ак өй! Мин андый кысан өйдә бер генә дә тора алмас идем, тыным буылыр иде,— дип әйтте ди.



УЛ ДА БУЛСА СЫЛТАУ

Дус булып йөрүче ике кызыйның берсе икенчесенең песи баласына бик кызыккан ди.

— Дустым, синең песиләрең икәү бит. Берсен миңа бирсәнә, синең төсең итеп асрармын,— дигән.

— Кайсысын аласың килә?

— Агын бирсәң дә ярый...

— Юк, анысын үзем бик яратам шул.

— Алайса, карасын бир!

— Бик бирер идем дә бит, яхшы түгел. «Үзең яратмаган нәрсәне бүләк итмә» диләр бит олылар. 28

ХӘЙЛӘКӘР

— Син мәктәптә дә укыйсың. Кошларны яхшы беләсең булыр инде, әйе бит?

— Шулай булмыйча...

— Алайса, әйт әле, энекәш, әнә шул елга буенда йөргән ике кошның кайсы чәперчек тә, кайсы уткойрык?

— Һи, аны да белмәсәң! Әнә ул уткойрык тирәсендә чүпләнеп йөргәне нәкъ чәперчек инде аның!..

ШҮРӘЛЕ КАЙДА ЯШИ?

— Бабай! Синең Шүрәлене күргәнең бармы?
— Бар.
— Кайда?
— Тукай китабында.
— Ә ул кайда күргән?
— Ул әкияттә күргән...

СЫНАУ

Ял көнне атасы газеталар караштырып утырганда кечкенә улы аңа сорау биргән.

— Әти, Мәсгут абый әйтә, синең башың бик шәп эшли, ди. Күрсәтче, ә, ничек шәп эшли икән ул?

— Беләсең ич, улым, бүген бит башның ял көне!.. — дип котылды атасы.

КҮЛӘГӘ

Шаян малай үзенең күләгәсен күрде дә аны үртәргә тотынды. Ул аның өстенә сикерде, янышнан йөгерде, тибеп очырмакчы булды. Ә күләгә, аны үзе үртәгәндәй маймылланып, гел малайның үзе шикелле кылана, әмма, һич тоттырмый, гел алга барып чыга иде. Ниһаять, малай тәмам арыды, тамагы ачыкты, ул өенә кайтырга булды. Борылып караса, күләгә дә аның артыннан кайтып килә.

— Әһә! Синең дә ашыйсың килдеме? Әйдә, алайса, киттек!... 30

КАЙСЫ АКЫЛЛЫРАК

Ишегалдында чүпләнеп йөргәндә ике яшь әтәч икесе берьюлы орлык таптылар.

— Мин беренче булып күрдем! — диде берсе.

— Юк, башта мин күрдем! — диде икенчесе.

Алар сугыша башладылар. Миләш ботагында утырган чыпчык җәһәт кенә очып төште дә орлыкны йотып та җибәрде.

— Их, сез, сугыш чукмарлары! — диде чыпчык.— Менә мин сезгә караганда нинди кечкенә инде. Шулай да юкка җәнҗал чыгарырга ярамаганны мин дә беләм.

ТАБЫШМАК

Бер бабай оныгының зиһенен сынап карарга булган.

— Ике эти, аларның ике улы үзара өч апельсин бүлешкәннәр. Һәркайсына берәр апельсин туры килгән. Кемнәр бүлгән апельсинны?

Оныгы башын бераз кашып торган да:

— Таптым! — дигән.— Апельсинны үзара бабай, эти һәм аның улы бүлешкәннәр.

— Мәрхаба, булдырдың! — дигән бабай.

НИЧӘ КОШНЫҢ ИСЕМЕН БЕЛӘСЕҢ?

Кунак булып килгән кардәшләре Кавигә бер пакет күрсәтеп шундый сорау бирде.

— Менә бу пакетта нәкъ егерме конфет. Әгәр шул конфет саны кадәр кош исемнәрен атый аласың икән, пакет синеке!

— Чыпчык, карга, саескан, сандугач, песнәк, тургай, күгәрчен, каз, этәч, тавык...

— Тукта! Булмады. Тавык белән этәч — икесе бер кош. Унны санадың, ә тагын?

— Тагын аларның ун чебиләре!..

Кардәш абый көлеп җибәрде дә пакетны Кавигә сузды:

— Мә, рәхәтлән, күчтәнәч синеке!



БАШЫҢНЫ ЭШЛӘП!



Мәктәптән кайтып килгәндә атасы очраган да аталы-уллы бергә кайталар икән. Атасы әйткән:

— Күрәсеңме, өй түбәсендә — өч күгәрчен. Я, әйтеп кара: әгәренки шуларның берсен карчыга тотса, өй түбәсендә ничә күгәрчен кала?

— Һи, аны да белмәскә! Икәү кала!

— Башыңны эшләт, улым! Берәү дә калмый. Ике күгәрчен куркудан очып китәчәк!

33

БӘХӘССЕЗ

Ике кечкенә малай, исләре китеп, кайры тун кигән бер дәү абыйга карап торалар.

— Нигә тунның җонлы ягы эчтә икән? Әнә сарыкның җонлы ягы тышта бит!

— Соң бу бит абый кеше, сарык түгел.

ГЕЛ САБАН ТУЕ ГЫНА БУЛСАЧЫ...

Сабан туе көнне иртән үк әнисе Тәнзиләгә яңа күлмәген, яңа туфлиләрен кидереп чәченә бантик такты да күзге алдына илтеп бастырды.

— Я әле, карап кара, танырсыңмы икән үзеңне!

— Ай, әни җаным! — дип кулларын чәбәкләде кызый.— Мин бүген кичәгедән дә чибәррәк. Их, гел шулай сабан туе гына булып торсачы!..

ӘТӘЧНЕҢ ВАКЫТЫ ЮК

Кечкенә сеңлесе абыйсына шундый сорау биргән ди.

— Бар тавыклар да күкәй сала. Ә нишләп әтәч тә күкәй салмый?

— Әтәчнең вакыты юк,— дип аңлатты ди абыйсы.— Аңа ишегалдында тәртип сакларга кирәк. Аннары ул әле, көне-төне кычкырып, тавыкларына сәгать ничә икәнне дә белдереп тора... Белдеңме?

ПЕСИНЕҢ ЯЛ КӨНЕ

Ике кечкенә малай үзара гәпләшәләр ди.

— Песинең дә эше бар бит, әйеме?

— Бар, песи дә эшли. Ул тычкан тота.

— Тик һаман-һаман түгел: әнә кичә безнең коридорда көпә-көндез тычкан чабып узды, ә песи, ичмасам, мыегын да кыймылдатмады, тик йоклап ятты.

— Ә, алайсам, аның ял көне булган инде...

35

КӘҖӘДӘН ТАРТЫП ЧЫГАРА

Шәһәр баласы авылда булып кайткан, дус-ишләренә авылда күргәннәрен сөйли ди.

— Әби миңа көн саен җылы сөт эчерде. Шундый да тәмле, шундый тәмле, телеңне йотарсың!

— Ул аны нинди кибеттән ала икән?

— Юк, бернинди кибеттән дә алмады, сөтне ул кәҗәдән тартып чыгарды...

ИКЕ МАКТАНЧЫК

Куян йомранны очратты ди.

— Син ни атлы? — дип сорады ди.

— Аю мин, аю! — дип әйтте ди йомран.— Ә син үзең ни атлы?

— Арыслан!

ЙӨЗ БАЛЫК

Малик дигән малайның мактанырга гел теле кычытып кына тора икән.

— Кичә без абый белән беләсезме олы күлдә күпме балык тоттык? Йөз балык? — дигән ул.

— Ай-яй күп тоткансыз! Ничек күтәреп кайта алдыгыз шул тикле балыкны? — дигәннәр күрше малайлары.

— Ә без аларны пыяла банкыга салдык...

НИГӘ ШУЛАЙ?

Нәни Алмаз бабасына сәер сорау биргән ди.

— Бабай, әйтче әле, нигә кешенең авызы белән теле берәр генә, ә күзе белән колагы икешәр?

— Шул сәбәпле,— дип әйткән ди бабасы.— Кеше азрак сөйләсен, күбрәк бүтәннәр сөйләгәнне тыңласын, дөньяны күбрәк күрсен!

37

ИКМӘКНЕҢ ИКМӘГЕ

Бер абый машинага төяп кырга тирес чыгара икән. Шәһәрдән килгән бер бала аннан сораган:

— Абый, машинаңа төягән нәрсә ул? — дигән.

Теге абый:

— Икмәкнең икмәге! — дип җавап биргән.

Әлеге бала моңа бик гаҗәпләнгән:

— Безнең шәһәрдә түгәрәк күмәч тә, кирпеч ипи дә, башкасын да саталар. Тик бу икмәкнең икмәген бер кибеттә дә күргәнем булмады,— дигән.

НИЧЕК БУЛА ИНДЕ УЛ?

Кечкенә малай атасы тирәсендә арлы-бирле килеп йөрде дә кинәт сорап куйды.

— Әти, син Гәрәй абыйны «җылы урынга урнашты» дигәниең. Малайлар әйтәләр, ул холодильникта эшли, диләр. Ә анда гел салкын. Ничек була инде ул?

— Анда Гәрәйнең кечкенә генә миче бар. Шунда ул гел кулларын җылытып тора...

КАРАКНЫҢ САЛАМЫ...

Бер әни өч баласын да янына чакырган да:

— Кайсыгыз базга төшеп каймак ашады? — дип сораган.

Балалар, авызларына су капкандай, дәшмәгәннәр. Шуннан соң ул хатын балаларының өчесенә өч салам тоттырган.

— Барыгыз, өчегез өч почмакка утырыгыз. Кем дә кем каймак ашаган, шуның саламы үзеннән-үзе озынаячак! — дигән.

Каймак ашаган малай «минем саламым озынаймагае» дип, аны бераз кыскартып куйган ди.

КАЙМАКНЫ КЕМГӘ ЯЛАТЫРГА

Сөт аерткач анасы кызына каймак бушаткан җамаякны биргән дә сөйләнә икән:

— Менә, кызым, мин сиңа шулай каймаклар да ашатам инде, болай да тәмле ризыклар бирәм. Дәү үскәч, син дә мине шулай сыйларсыңмы икән соң?

— И әни, мин дә синең шикелле булырмын инде. Син бит каймакны, әнә почмакта утырган әби яныннан узып, миңа китереп бирдең. Мин дә шулай каймакны кызыма бирермен инде.

АТТА ТҮГЕЛ, ТӘРТӘДӘ...

Бер малайны ат өстендә йөрергә өйрәтә башлаганнар. Малай бераз гына бара да егылып төшә, бераз гына китә дә мәтәлеп төшә икән. Алҗып беткәннәр. Әтисе аны оялтмакчы булган:

— Ат өстендә утыра белмәгәч, нинди егет инде син! — дигән. Малай моңа бик хурланган.

— Үзегез әйбәтләп атландыра белмисез дә миңа сылтыйсыз...— дигән.





УРЫНЛЫ СОРАУ

— Әни, шакал нинди хайван ул: этме, бүре шикеллеме?

— Ни сәбәпле алай дип сорыйсың, улым?

— Әти әйтә: «теге шакал-ревизор тагын талап китте. Ике казны, бер пар үрдәкне берьюлы каптырды», ди.

ШӘМСИЯНЕҢ ИКЕНЧЕ ЙӨЗЕ

Шәмсия апасы килгәч, кечкенә кызый аңа сыный карап торды да кинәт кенә сорап куйды:

— Апа, ә синең икенче йөзең кая соң? — диде.

Шәмсия моңа бик гаҗәпләнде.

— Ай, сеңлем, нинди тузга язмаганны сөйлисең? Ниткән икенче йөз тагын ул?

— Нигә, алайсам, әни шулай ди?

— Ничек ди?

— Безнең Шәмсия ике йөзле! — ди.



КЕМНЕКЕ КӘМИТРӘК?

Ике малай капка төбендә шыпырт-лап кына өйдәге хәлләр турында сөйлә-шәләр икән.

— Беләсеңме, бүген безгә доктор апа килде,— ди икән берсе.— Әти аңа телен чыгарып күрсәткән иде, доктор апа кәгазь язып бирде.

— Ә безнеке киресенчә,— ди икән икенче малай.— Башта доктор апа кәгазь язып бирде, әти аның артыннан гына телен чыгарып күрсәтте...

СУДАН КОРЫ ЧЫГЫП БУЛАМЫ?

Сельпо кассиры көпә-көндез алмагач күләгәсендә йоклап ята икән. Күрше малае моны күргән дә аңа лейкадан су сиптерә башлаган. Кассир ялт сикереп тормасынмы?

— Нәрсә кыланасың, малай актыгы, яңагыңа кирәкме?

— Юк, миңа берни дә кирәкми, Габдерәхим абый! — дигән малай.— Сине һаман-һаман судан коры чыга, диләр. Ничек була икән ул? Син ачуланма инде, шуны беләсем килеп кенә сиптердем.



АКЫЛЛЫ КИҢӘШ

Сабитның ата-анасы үзара гел бәхәсләшәләр икән.

— Син баланы бозып бетердең! — дип шелтәли ди ирен анасы.— Мин ныграк орыша башладыммы, син баланы үз янына чакырып, башыннан сыйпарга, иркәләргә тотынасың!

Атасы да үз сүзен бирми ди.

— Юк, син бозасың баланы! Мин каешка үрелә башладыммы, син малайны кочаклап аласың...

Сабит мондый әрепләшүләрдән туеп беткән дә әйткән:

— Эш чыкмады сездән! Берегез алай, берегез болай ди. Әйдә, булмаса, мин үзем тәрбиялим сезне! — дип әйткән ди.

САБЫЙНЫҢ ГАДЕЛЛЕГЕ

Күрше кешесе әҗәткә акча сорарга кергәч, әти кеше борчылган кыяфәт белән кулларын җәеп җибәрде:

— Бик бирәсе дә бит, күрше, нихәл итим? Йортта елап эзләсәң бер тиен акча калмады! — диде.

Әтисенең әйтеп бетерүе булды, арага кечкенә малай килеп кысылды.

— Әти, әти, оныттыңмыни? Шкафтагы борынсыз чәйниктә бар бит әле безнең акча!

— Аһ, шайтан гына алгырысы! — дип атасы бот чапты.— Чыннан да онытканмын бит!

ТАВЫШ НИДӘН ЧЫГА

Бер малай күрше кызы белән уйнаган җиреннән, нидер исенә төшеп, әнисе янына йөгереп кайтты.

— Әни, без Рәмзия белән әти-әни булып уйныйбыз. Ул аш пешерә, мин газетлар укыйм, телевизор карыйм. Тик без әти белән әни арасында ничек «тавыш» чыгуын гына белмибез.

— Таптың сүз...— диде әнисе.— Менә әтиең ягыннан әбиен генә керсен. Ул һәммә нәрсәгә бәйләнә: тегесе тегеләй түгел, монысы болай түгел, теге дә бу...

Ул арада телевизор яныннан әти кешенең тавышы ишетелде:

— Ышанма, улым, дөрес түгел! Менә синең Зөбәйдә әбиең, ул чыннан да безнең башка бәла инде...

— Син шаярткканны аңламыйсың, уен турында сүз бара! — диде әнисе.

— Ә син минем әнигә тел-теш тидермә! — диде әтисе.

— Җитте, мин аңладым инде! — диде малай. Шундук күрше кызы янына уйнарга кереп китте.

ҮЗ СҮЗЕҢӘ ҮЗЕҢ ХУҖАМЫ?

Бабай кеше үзенең оныгын орыша икән.

— Нинди тәрбиясез бала син, ә? Иң әйбәт дустың белән сугышкансың. Син бит миңа сүз бирдең: моннан соң тату гына уйнармын, дуслыкны бозмам, дидең. Вәгъдәсез малай син, үз сүзеңә үзең хуҗа була белмисең! Оят!

Оныгы кашларын җимереп үзенекен кабатлаган:

— Хуҗа була беләм! Сүз минекеме? Минеке! Хуҗа булганга күрә дә мин аны хәзер кире алдым!..

ТӘБИЯ ТАНСЫГЫ

Төнге сменага эшкә барыр алдыннан әни кешегә азрак ял итеп алырга кирәк иде. Әмма улы янына җыелган бала-чага бик яман чыр-чу килә башлагач, ул аларга күршеләргә кереп торырга кушты.

— Анда телевизор да карарсыз,— диде.

Тик улы тиз үк кире борылып кайтты.

— Әни, нәрсә дигән сүз ул? Гадилә апа безгә «Менә тәбия тансыклары. Сезне генә көткәнием!» диде.

КИРЕ МАЛАЙ

Ул малай шундый кире булган, ата-анасы кушканны колагына да элмәгән ди. Шунлыктан аңа киресен әйтеп уңайга эшләтә торган булганнар. Өйгә утын кертәсе булса:

— Утын кертмә, улым, суга барма...— диләр икән, малай нәкъ киресен эшли икән.

Беркөнне шулай базарга барганда болар елга аша чыгалар икән, кинәт яңгыр явып ташу килеп төшкән дә болар

45 бата башлаганнар. Атасы алданрак чыккан да улына озын такта сузган.

— Улым, ябышма тактага, ябышма! — дип кычкырган.

Малай, «тукта, гомеремдә бер генә тапкыр булса да этинең сүзен тыңлыйм әле!» дип тактаны этеп җибәргән. Шундук су астына төшеп тә киткән ди.

ӘБИ КИҢӘШЕ

Әби:

— Мәктәбеңә барыр вакытың җитте, улым, кузгал!

— Әем, барасым килми. Анда икеле куялар.

— Бар, улым, бар! Бармасаң, берлесе дә эләкмәс...

БЫЛТЫРГЫ «А»

Бер ялкау малай класста икенче елга утырып калган. Икенче уку елы башланган көнне укытучы апалары кара тактага зур итеп «А» хәрефен язып куйган ди. Бу малай бик гаҗәпләнеп карап торган-торган да:

— Апа, былтыргы «А» бит бу! — дип кычкырып җибәргән ди.

АҢЛАТКАН

Беренче класста укучы малай атасы белән урамнан барганда аларга бөкрәеп бeткән бер карт очраган.

— Әти, беләсеңме бу бабай нигә шулай бөкре булып калган? — дигән малай.

— Белмим шул. Нишләп икән?

— Ул мәктәптә укыганда парта артында дөрес утырмаган...

ЧЫН КҮҢЕЛДӘН

Мәктәптә укытучы Закирга шундый сорау биргән:

— Синең абыең бакчагыздан ун алма алып чыкты ди. Шуларның өчесен үзенә алды да калганнарын сиңа бирде ди. Әйтче әле, абыең сиңа ничә алма биргән була?

Закир кашларын җимереп утырды да башын селекте ди.

— Ул миңа гомердә шул хәтле алма бирәчәк түгел.

Укытучы елмаеп куйды да башкача итеп сорады ди.

— Алайсам, абыең түгел, син алып чыктың ди ун алма. Үзеңә өчне калдырдың. Абыеңа ничә алма биргән буласың?

Закир янә башын селекте ди.

— Мин дә аңа ул тикле алма бирмәсием...

БЕРГӘЛӘП ЫҢГЫРАШТЫК

Бер көнне Әсгать мәктәпкә бармый калган. Икенче көнне укытучы:

— Нигә син кичә дәрескә килмәдең? — дип сораган.

— Бушый алмадым, абыйның теше сызлады,— дигән Әсгать.

— Соң бит синең тешең түгел, абыең теше сызлаган ич!

— Булсани! Аңа булышырга кирәк иде бит! Без абый белән икәүләшеп ыңгыраштык...

ТАГЫН СЕЗГӘ НИ КИРӘК?

Борын-борын заманда алты-җиде яшьлек малайны абыстайга сабакка йөртә башлаганнар. Ул чакта укыткан өчен абыстайга атна кич саен бер кәнди он алып бара торган булганнар.

Байтак кына укыганнан соң, атасы-анасы малайны чакырып алганнар да:

— Я әле, нәрсәләр өйрәндең икән, укып күрсәт! — дигәннәр.

Малай бик үткен икән, ишеткән-белгәнен, исендә калганнарын һәммәсен бергә укмаштырып укып та җибәргән ди.

— Бисмиллаһи вә биллаһи, артабатын иләйһи, аннары галәйһи, янә дәхи валлаһи, иң соңыннан төрҗәгу-ун-н...— дип сузып куйган ди.

Ата-аналары улларының китап сүзләрен шулай чатылдатып укып бирүен бик ошатканнар. Тик аларга бу укыганнар азрак кебек тоелган.

— Бары шул гынамы? — дигәннәр.

— Нигә, җитмәгәнмени? Сезнең бер кәнди оныгызга дилбегә буе итеп укытмаслар инде...— дигән малай.

МИНЕМ ӘТИ СӨЙЛИ

Ирек исемле бер малайның мәктәпкә барасы килми, ялкавы җибәрми икән. Аның башына бик шәп бер уй килеп, ул телефонны эшкә җигәргә булган.

— Мәктәпме бу? Әһә! Директор абый, Ирекнең бүген башы авырта, ул мәктәпкә бара алмый. Кем сөйли дисезме? Бу Ирекнең этисе сөйли...

Ләкин директор абый бик коры гына тотып Ирекка хәзер үк мәктәпкә килергә кушкан.

АТАСЫ ҺӘМ УЛЫ

Улы мәктәптән кайтуга атасы аннан:

— Я әле, Фәрит, мәктәптәнниләр алып кайттың? — дип сораган. Малай кулын гына селтәгән:

— Әй, җыен вак-төяк. Син үзең ир-ат вак-төяк турында сөйләшеп тә тормый, дисең бит...

АҢЛАШЫЛА...



Укытучы Рәсимнең дәфтәрендә зурлар кулы белән язылган саннар күреп шикләнә калды.

— Рәсим, тактага чык әле! Синең әбиең арифметикада суда йөзгәндәй йөзә диләр. Дөресме?

— Һи, юк сүз ул! Әби бер генә мәсьәләне дә чишә алмый! — диде Рәсим.— Ә менә бабай — молодец! Күзен төшерүе була, шундук «әһә! Аңлашыла...» — ди.

— Аңлашыла...— дип сузып әйтте укытучы да.

ПЕСИГӘ — ИКЕЛЕ

Укытучы дәфтәрләрне карап чыкты да:

— Котдус! Нишләп син өйгә бирелгән сабакны эшләп килмәдең? — дип сорады.

Котдус кызарынып аягүрә басты.

— Эшләвен эшләгәнием мин. Тик песи генә харап итте! Өстәлгә сикереп менде дә дәфтәр өстенә каймаклы стакан аударды!

— Шулаймы? Кара син ул явыз песине! Менә алайса шуның өчен аңа икеле!..

ИҢ ТӘМЛЕСЕ...

Җәйге каникул вакытында тычкан балалары очырмага менгереп ташлаган дәфтәрләрне кимерергә тотынганнар. Әни-тычкан балаларын бик мактаган ди:

— Булдырасыз, шәп укыйсыз, тырышасыз,— дигән.— Шулай да арада иң яратып укыганыгыз кем дәфтәрләре булды?

— Барласныкы! — дип чәңгелдәде бер тычкан баласы.

— Кит аннан, сөйләмә юкны! Барлас бөтен мәктәптә иң ялкау, иң тәртипсез малай бит ул! — диде икенчесе.

— Булса соң! — диде әлеге тычкан баласы.— Аның каравы Барласның дәфтәрләре бик тәмле. Аларга я татлы бал, я бүтән берәр тәмле ризык ягылган була.

КЫЗАРГАН...

Улының мәктәптән кашларын җимереп кайтуына борчылып әнисе аңа сорау бирде:

— Ни булды, улым? Нигә авызыңны турсайттың?

— Турсайтмассың, бар! Синең өчен кызарырга туры килде анда. Мәсьәләне ялгыш чишкән өчен укытучы сиңа икеле куйды...

БУЛЫШКАН...



Атасы эштән кайтканнан соң, малаеның башыннан сыйпап, хәл-әхвәл сорашырга тотынган.

— Я, бүген ни эшләр бетердең? Уйнарга чыктыңмы? — дигән.

— Юк, беркая да бармадым.

— Нишләдең генә соң?

— Мин әнигә минем өйгә биргән мәсьәләләремне чишәргә булыштым...

ГЫЙБРӘТЛЕ МИСАЛ

Укытучы мәктәптә балаларга:

— Укый-яза белмәүнең зарары турында берәр мисал китерегез! — дигән.

— Мин беләм! — дигән бер бала.— Әгәр чебен укый-яза белсә, ул «мухомор» дип язылган кәгазьгә кунмас иде...

БЕР ҮК БҮРЕ

Галинең иншасын укып караганнан соң укытучы аны шелтәләп:

— Синең язганың сүзмә-сүз Вәлинеке бит! Күчереп язарга ярамаганны белмисеңмени? — дигән.

— Юк, күчереп язмадым мин, апа. Без бит икебез дә бер үк бүре хакында яздык. Шуңа күрә охшагандыр! — дигән.

МӘКТӘПТӘ

Укытучы балаларга җылы белән салкынның нәрсә булуын аңлатып шуңа тормыштан мисаллар китерергә кушкан. Бер бала әйткән:

— Нигә, бик ансат ул! — дигән.— Кышын нигә көн кыска була? Һава салкын булганлыктан, көн кысыла торгач, гүпчи кыскарып кала. Ә җәй көне нәкъ киресенчә, һава җылынгач, көн дә иркенәеп, җәелеп китә дә үзеннән-үзе озая...



ФАМИЛИЯНЕ КОРБАН ИТЕП...

Мәгариф бүлегенең инспекторы белән мәктәп директоры урамнан баралар икән. Койма буена утырткан канәфер чәчәген ботарлап маташучы бер малайга күзләре төшкән.

— Менә тәрбия нәтиҗәсе! — дигән инспектор.

Директор кызарынып әлеге малайга:

— Хәлитов! Нишләвең бу? — дип кычкырган.

— Әти, безнең фамилия Хәмитов бит, оныттыңмыни? — дигән малай.

КЫЕК СӨЙЛӘМ

— Әни, Әхмәт мине гел үчекли, авызын кыйшата! — дип зарланган кечкенә Кәрим.

— Улым, шаярып утырма! — дигән әнисе.

— Шаяраммы? Өйгә бирелгәнне эшләп утырам ич! — дигән Әхмәт.— Укытучы туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндереп килергә кушты.

И ЗАМАНА, ЗАМАНА...

География дәресендә бер укучы Кавказ тауларын Һиндукуш белән бутаган, картада Африка чүлләрен Боз диңгезеннән эзли икән.

— Булмады бу! Әйдә, үз якларыбызга кайтыйк. Волга белән Жигули кайда?

— «Волга» күрше абый гаражында, ә «Жигули» безнекендә...

МЕНӘ ТАМАША 56

Укытучы дәрестә балаларга яңа тема аңлаткан.

— Барыгыз да аңладыгызмы? — дигән.

— Юк, аңламадык! — дигәннәр укучылар.

Икенче мәртәбә аңлатып чыккан да тагын сораган:

— Инде аңладыгызмы?

Балалар тагын хор белән:

— Юк, аңламадык! — дип җавап биргәннәр.

Укытучы өченче мәртәбә аңлаткан да:

— Инде шәт аңлагансыз бит?! — дигән.

— Юк, бу юлы да аңламадык әле! — дигәннәр.

Укытучы моңа бик аптырап башын кашырга тотынган.

— Мин инде хәтта үзем дә аңладым. Ә сезгә һаман да барып җитми әле. Менә тамаша! — дигән.

ББК 84(2Р-6Тат)-4
Б 33

Ю. ДЕНИСОВ
рәсемнәре

Кече яшьтәге балаларга

Кетеки тел бистәләре: Мәзәкләр.— Казан: Татар. кит. нәшр.,
Б33 1993.— 56 бит.
ISBN 5—298—00811—9

Бу җыентыкка балалар да, өлкәннәр дә мавыгып укырлык шаян мәзәкләр тупланган. Аларның кайсылары көлдерә, күңелне хушландырып җибәрә, кайберләре исә, берәр гыйбрәтле хәлне искә төшереп, сагайтып куя. Мәзәкләр — халыкның бетмәс-төкәнмәс күңел байлыгы, шул ук вакытта алар халык теленең сафлыгын да саклап киләләр.

Б $\frac{4803560204—036}{М132(03)—93}$ —139—91

ББК 84(2Р-6Тат)-4

ISBN 5—298—00811—9

© Гомәр Бәширов, төзүче һәм әдәби эшкәртүче, 1993.
© Ю. Денисов, рәссам, 1993.

Издание для детей и юношества

ПРОКАЗНИКИ

Мэзэки, короткие юмористические рассказы

(на татарском языке)

Мөхәррире ***Т. Нурмөхәммәтов***
Рәссам-мөхәррире ***Ф. Хәсьянова***
Техник-мөхәррире ***С. Әхмәтҗанова, М. Абитова***
Корректоры ***Х. Фәйзрахманова***

ИБ № 6005

Җыярга тапшырылды 13.11.90. Басарга кул куелды 17.12.93. Форматы $70\times90^{1}/_{16}$. Офсет кәгазе № 1. Гарнитурасы «Т. Таймс». Офсет басма. Шартлы басма табагы 4,68. Шартлы буяу-оттиск 19,86. Нәшер-хисап табагы 3,03. Тиражы 25 000 экз. Заказ П-497. Бәясе ирекле.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан Республикасы информация һәм матбугат министрлыгының К. Якуб исемендәге полиграфия-производство берләшмәсе.
420111. Казан, Бауман ур., 19.

КИТАП УКЫРГА ЯРАТУЧЫ ЯШЬ ДУСЛАРЫБЫЗ!

Татарстан китап нәшрияты 1992—1993 елларда сезнең һәм шулай ук эти-әниләрегез өчен түбәндәге китапларны басып чыгарды һәм чыгарачак:

ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТАРИХЫ.
Пәйгамбәрләр һәм аларның гыйбрәтле тормышы турында гаҗәеп риваятьләр. Рәсемнәр белән.

ИДЕГӘЙ.
Татар халык дастанының балалар өчен махсус эшләнгән варианты. Ул, укый башлау белән, борынгы чал чорга алып китә. Мавыктыргыч маҗаралар, канкойгыч сугышлар, хан сараендагы ызгыш-талашлар белән тулы ул. Дастанның төп фикере — Ватанны күз карасыдай саклау.

Әхмәт Фәйзи. **КЕЧКЕНӘ АПУШ.**
Татар балалар прозасының алтын хәзинәсенә кергән бу романда бөек шагыйребез Г. Тукайның ятим балачагы һәм авыр язмышы турында сөйләнә.

МӘДРӘСӘЛӘРДӘ КИТАП КИШТӘСЕ.
Мәшһүр мәдрәсәләребезнең тарихы, эшчәнлеге һәм аларда укыган атаклы әһелләребезнең язмышлары турында.

БАЛАЛАР ФОЛЬКЛОРЫ.
«Татар халык иҗаты» сериясенең 13 нче томы.

ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕ.
Китап төсле рәсемнәр белән бизәп чыгарыла.

К. Насыйри. КИТАП-ӘТ-ТӘРБИЯ.

Бөти урынына тотарлык бик изге китапчык бу. Өстәвенә матур рәсемнәр белән дә бизәлә. Балалар, әти-әниләреннән акча сорап, аны аларның үзләренә үк алып кайта һәм: «Безне шушы китап буенча тәрбияләп карагыз әле»,— дип әйтә алалар.

К. Нәфыйков. ҮТКӘНГӘ СӘЯХӘТ.

Автор нәкыш сәнгате аша татар халкының тарихын тасвирлап күрсәтә.

ЙӨРТӘ БЕЗНЕ ЯЗМЫШЛАР...

Эмигрант сүзе әлек күңелне шөбһәләндерә иде. Югыйсә алар үз ватаннарын теге яки бу сәбәп белән ташлап киткән һәм гомерләре буена туган илләрен сагынып яшәгән газиз җаннар бит. Бу китапта дөньяның төрле почмакларына таралышкан милләттәшләребезнең үткәндәге язмышлары һәм бүгенге көндәге тормышлары тасвир ителә.

М. Сәхәбетдинов. ТАТАР КӨРӘШЕ.

Халкыбызның милли көрәше һәм көрәшү алымнары турында.